ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 17 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасы өстәп, үзгәреш кертергә:

«з) тимер юл транспорты өлкәсендә табигый монополия субъекты тарафыннан гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга граждан-хокук шартнамәләре төзелгән юридик затлар гамәлгә ашыра торган шушы эшләрне башкару максатларында кирәкле гомумталалган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен гомумталалган файдалы казылмалары булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү турында;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 04 октябрь
№ 68-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ